*#студентлардөньясы*

# *Көллият сулышы*

**№ 6**

**03/2023**

## 8 НЧЕ МАРТ

**ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ**

*Гүзәл затлар! Сезне хөрмәт итеп,*
*Тәбрик итәм ихлас күңелдән.*
*Чәчкәләргә төреп, бик бәхетле,*
*Гомер телим йөрәк түремнән…*

*Киләчәктә барыр юлыгызны,*
*Урасын тик шатлык, мәхәббәт,*
*Язмышыгыз нурлы, назлы булсын,*
*Җанда булсын саулык, бәрәкәт!*

# *Я Ң А Л Ы К Л А Р*



3 нче мартта яраткан кием салоны “Метелица” һәм Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте катнашында матурлык һәм талант бәйгесе “Мисс Метелица – 2023” узды. Җиңүчеләр:

Мисс Метелица 2023 – Яруллина Лиана

I Вице-Мисс – Зиннәтуллина Эмилия

II Вице-Мисс – Варламова Анастасия

Мисс тамашачылар симпатиясе (онлайн тавыш бирү) җиңүчесе – Крайкова Екатерина

---




14-16 нчы март көннәрендә Зур Әтнәдә ел саен үткәрелә торган “Созвездие-Йолдызлык – 2023” ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең зона этабы узды.

Фестиваль нәтиҗәләре буенча:

1 урын – “Арча егетләре” халык вокаль ансамбле;

2 урын – Зиннәтуллина Эмилия;

3 урын - «Язгөл» вокаль ансамбле.

Котлыйбыз! Финалда уңышлар телибез!

---



30 нчы мартта Саба аграр көллияте актлар залында “Әйдә ШаяРТ” татар лигасының зона этабы узды. Барлыгы 7 команда көч сынашты.

Безнең Арча командасы уңышлы гына чыгыш ясап,

1 нче урынга лаек булды. Котлыйбыз!

Алга таба да иҗади уңышлар телибез!

# ОСТАЗЛАРНЫҢ ИСЕМЕ МӘҢГЕЛЕК



22 нче март көнне Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең "Әлифба" музеенда "Әлифба" дәреслегенең авторы Рәмзия Вәлитованың тууына 109 елга багышланган әдәби кичә үткәрелде.

Чараны көллиятебез директоры Гарипова Гөлнара Фидаил кызы ачып җибәрде. Очрашуга Рәмзия Гыйләҗевнаның укучылары – Сафина Савия Сабир кызы, Абдуллина Кәүсәрия Габделбар кызы, Минхайрова Ольга Иван кызы, Шәрипова Нәкыя Гайфетдин чакырылган иде. Аларның һәрберсе мөгаллимне җылы һәм рәхмәт сүзләре белән искә алдылар. Һәм, әлбәттә, Рәмзия Гыйләҗевнаны искә алып, кунаклар искиткеч педагог, тормыш иптәше – Сәлай Гатат улы Вәгыйзовны да читләтеп үтмәделәр. Шулай ук алар белән бергә дус-тату эшләгән хезмәттәшләре – ветеран укытучыларыбыз – Сәгъдиев Илдус Габдрахман улы, Сәгъдиева Флера Гомәр кызы, Камалетдинова Сания Сибгатулла кызы һәм башка укытучылар да эшләү дәверендә булган якты хатирәләрен, кызыклы мизгелләрен кабаттан яңарттылар, студентларыбызга Әлифба авторлары турында күп мәгълүмат бирделәр.




Кичә бер сулышта узды һәм һәр кешенең күңелендә якты хатирә булып уелып калды.

**Шиһабеддинова Г.Х.**

# И Ж А Т

**# ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ**



**Иванова Эльвина**

**113 нче төркем студенты**

**Бәхетнең асылы**

Мин шатмын бу дөньяга,
Яшәр өчен килгәнгә.
Җиһанны кочып кулга,
Бәхетле яшәгәнгә.

Тормыш авырлыкларына
“Мин беренче”, - диеп әйткәнгә.
Яшьлегемнең кышларына
Курыкмыйча кергәнгә.

“Шөкер”, - диеп, кузне ачып,
Бу җәннәтне кургәнгә.
Горур аякларымда басып,
Туган жирдә үскәнгә.

Халыкара хатын-кызлар көне
Тирә-юньгә карыйк, әйдәме?
Кыз сөенә, онытылган өне,
Ә кулында лалә бәйләме.

Күпме бәхет аның карашында,
Күпме наз һәм жылылык.
Бәхет кошы аның кулларында,
Югалмасын иде ул шатлык!

Янган күзләр, яшьли әйткән сүзләр
Мәңге кереп кала хәтергә.
Ник тиз үтә икән ул мизгелләр,
Авыр итеп күңелгә?

Хатын-кыз ул кояш сыман,
Кышкы җиһанны эретә.
Аңа карап елмаюдан,
Китек күңелләрең бәйләнә.

Елга бер генә килсә дә,
Истә тотыйк язның бәйрәмен
Онытмасак иде көн дә,
Хатын-кызның кадерен!

# УКЫТУЧЫ БУЛУ – ШӘП!


*28 нче март көнне “Укытучы булу – шәп!” дип аталган I республика психологик-педагогия сыйныфлары слетына старт бирелде. Бу уңайдан КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына укытучылар, сыйныф җитәкчеләр һәм педагогик юнәлештә укучылар җыелды. Әлеге чарада көллият директоры Гөлнара Фидаилевна Гарипова катнашты. Үз чыгышында ул көллиятнең гимназия сыйныфлары эшчәнлеге турында сөйләде. Уку елы башыннан Арча педагогия көллияте Татарстан Республикасының 10 районында әлеге классларның кураторы дип игълан ителде.*

*Әлеге чарада Арча педагогия көллиятенең 9 нчы сыйныф гимназия укучысы Абдуллина Диләдә “Гимназия сыйныфлары эшчәнлеге” темасына чыгыш ясады. Көллият каршындагы гимназия сыйныфында уку аның хыялын тормышка ашырырга – укытучы булырга мөмкинлек бирә дигән фикер яңгырады.*

***Гыйләҗева А.Ф.***



# БАШ ВАТЫП АЛАБЫЗМЫ?






***Сулдан уңга:***

*1.Студентларның алган билегеләрен теркәп бару өчен кирәк булган җиһаз.*

*3.Студентларның гел онытылып кала торган бик мөһим әйбере?*

*6.Белемне тикшерү өчен үткәрелә торган эш.*

*8.Сөйләгән мәгълүматны теркәп бару өчен кирәкле җиһаз.*

***Өстән аска:***

*2.Югары һәм урта һөнәри белем бирү йорты укучысы.*

*4.Студентларның яраткан ризыгы.*

*5.Һәр ярты ел саен студентларның укымый торган вакыты.*

*7.Студентларның имтиханнар бирә торган чоры.*

*9.Студентлар көне үткәрелә торган ай.*

*10.Укучыга кирәк булган һәрбер мәгълүматны бу әсбаптан табып була.*

**Редколлегия:** Шиһабеддинова Г.Х.

Гыйләҗева А.Ф., Иванова Э., Халикова К., Хәкимова Я.